# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пункты территориясендәге Волгоград урамында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

24.11.2025 №2

«Бердәм хакимият системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 һәм 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы торак пунктының бер өлешендә гражданнар җыены
КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пунктының бер өлешендә Волгоград урамында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 10 000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Яр буе Морквашы торак пункты чикләрендә Волгоград урамында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х.Гаязов